**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы № 22 15 март, 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-36 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәреш кертү хакында (2015 елның 18 августындагы №148-83, 2015 елның 29 октябрендәге №12-3, 2018 елның 24 апрелендәге №91-46, 2018 елның 13 ноябрендәге №115-57, 2018 елның 17 декабрендәге №120-60, 2019 елның 25 июнендәге №137-68, 2019 елның 5 ноябрендәге №147-72 карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Сарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-36 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» (2015 елның 18 августындагы №148-83, 2015 елның 29 октябрендәге №12-3, 2018 елның 24 апрелендәге №91-46, 2018 елның 13 ноябрендәге №115-57, 2018 елның 17 декабрендәге №120-60, 2019 елның 25 июнендәге №137-68, 2019 елның 5 ноябрендәге №147-72 карарлар редакциясендә) карарына 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә.”.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында” http://pravo.tatarstan.ru веб-

адресы буенча һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://aznakayevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.Р.Шәрипов